**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

“28” ноябрь 2020 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кышлау торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Кышлау авыл җирлеге территорисендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

– Кышлау авылы зираты территориясен киртәләп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү;

- бензин триммеры сатып алу.

2) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- Кышлау авылы территориясен чистарту, Татарстан һәм Чапаев урамнары арасындагы күпер буенда агачлар һәм куаклар кисү, транспорт хезмәтләре күрсәтү, килешү буенча хезмәт хакы түләү;

- урам утын карауга хезмәт хакы түләү;

- тукталыш мәйданчыгын ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы өчен түләү.

3) Кышлау авылы скверын төзекләндерү:

- газон чабу, утырту материалы алу, яктырткычлар сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү.

4) физик культура һәм спортны үстерү:

- хоккей тартмасын ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кышлау авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Кышлау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Шакирова Р.Ф.